# Чишмә башы

**4 нче сан, февраль**

**Хәсәншәех балалар бакчасы**





**Февраль ае бакчабызда хәрби-патриотик һәм туган тел айлыгы буларак үтте. Балалар белән үткәрелгән чаралар аларда патриотлык хисе , туган илебезгә туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләүгә багышланды.**

**Туган тел – туган җир, Туган ил төшенчәләренең төп мәгънәсен бала аңына җиткерүче иң мөһим чара. Балаларга патриотик тәрбия бирү туган телдән башка мөмкин түгел. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып-белүе һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның туган телен – ана телен белүенә бәйле. Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә Туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбарәт.**

# Герой шагыйрь – Муса Җәлил

















Муса Җәлил-олылыр һәм балалар өчен иҗат иткән бөек шагыйрь. Без аның иҗаты белән кечкенә яшьтән үк таныша башлыйбыз. Шагыйрь әсәрләрендәге геройлар кебек илгә, халыкка тугърылыклы, намуслы, дус, бердәм булып үсәргә өйрәтү – төп бурычларыбызның берсе. Бакчабызда узган туган тел айлыгы кысаларында балаларыбыз, авыл китапханәсенә барып, Муса Җәлил китаплары белән таныштылар. Республика күләмендә шигырь конкурсларында катнаштылар. Патриот шагыйрь Муса Җәлил иҗатына багышланган "Кызыл ромашкалар" шигырь сөйләү бәйгесендә Фахретдинова Язгөл Әнис кызы 1 нче дәрәҗә лауреат,Хлопушин Данир Фәнис улы һәм Сафина Сәмирә Рифат кызы 3 нче дәрәҗә лауреат дипломнарына ия булдылар. Җитәкчеләре - Хисамиева Ләйсән Илсур кызы. Котлыйбыз! Бу чараларга күп көчләрен куйган әти-әниләренә зур рәхмәт!

# Бездә күңелле








“ АҖАГАН” уены

Мәктәптә укыган чагымда ел саен Аҗаган уены оештырыла иде. Мәктәптәге барлык укучылар алдан ук ике командага бүленә, җырлар, маршировка өйрәнелә башлый иде. Әлбәттә ул командаларның берсенең исеме Муса Җәлил була.

Салют сиңа Муса Җәлил

Салют иң яшь буыннан...Погоннар, мылтыклар, маскалар... Болар һәркемдә дә булырга тиеш. Юкса, балл киселә. Балл кисүчеләргә караш икенче була инде, чамалыйсыздыр.Ул кыр кухнясы... Урман буенда, кырда көлдә пешкән бәрәңге, учакта кайнаган чәй тәмен әле дә сагынам.

Быел гаиләбез белән тагын шул вакытка кайтып килдек. Тырыша-тырыша мылтыклар ясадык. Погоннар әзерләп тактык. Җылы бияләй, киемнәр барладык, итекләрне дә эзләп таптык, чөнки балалар бакчасында Аҗаган уены булды. Кечкенәләр ягында йөрүче улым "мин дә катнашам, миңа да мылтык, гранаталар кирәк" дип икешәрне ясатты әтисенә. Киемнәрен дә әзерләтте. Бөтен хыялы зурлар белән Аҗаганда катнашу иде. Баланың теләгенә каршы килмәгән тәрбияче апалар, аны да уенга кушканнар.

Фотолардан гына күрсәк тә, балаларның шатлыгы йөзләренә чыкканын анларга була, чөнки ул көнне күпләр өйләреннән "мин бүген садикка түгел, солдатка барам" дип чыгып киткән.Баланың хыялына каршы килмәүләренә бер сөенсәм, бакчабызда патриотик тәрбия бирелүенә мең куанам. Ватаныңа, туган җиренә мәхәббәт, хөрмәт гаиләдән башланса, нәкъ менә бакчадан дәвам итә. Патриотик тәрбия әхлак тәрбиясе кебек үк бик кирәк.

Тәрбиячеләребез! Рәхмәт сезгә безне хыялларда гына булса да балачакка кайтарганыгыз өчен! Рәхмәт сезгә балаларыбызга биргән белем һәм тәрбия өчен! Иң мөһиме - рәхмәт балаларның күзләрендәге шатлык очкыннары өчен!

Гөлзилә Фәхретдинова





# *Туган телем сагында*







21 февраль – Халыкара туган тел көне. Дөнья халыклары 6 мең телдә сөйләшә. Һәркем өчен дөньядагы иң кадерлесе – беренче сөйләшә башлаган аңа теле. Халыкара Туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип таныла.Туган тел - һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырылмый торган “әни”, “әти”, “әби”, “бабай” сүзләрен башлап туган телдә әйтәбез. Туган үскән ил- җирнең якынлыгын Ватанның газизлеген без туган тел ярдәмендә тойганбыз. Шагыйрьләребезнең матур-матур шигырьләрен ятлап, әле дә куанабыз, рухланабыз.Барыгызны да халыкара туган тел көне белән котлыйбыз. Татар халык мәкале: “Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр”, – ди. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк, чөнки милләтнең яшәешендә туган тел иң мөһим урыннарның берсен алып тора.

Бакчабызда мәктәп белән дәвамчанлык эше дә системалы рәвештә алып барыла. 28 февраль көнне бакчабызда мәктәбебез укытучылары өчен ачык чаралар үткәрелде. Кечкенәләр төркеме 'Теремкәй"әкиятен сәхнәләштерделәр, зурлар патриотик темага ачык шөгыль һәм җыр-биюгә осталыкларын күрсәттеләр. Балаларыбызның тырыш, уңышка омтылучан булулары әти-әниләр өчен дә, тәрбиячеләре өчен дә сөенерлек.



